МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

9 июль 2018 ел № М 299

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезнамәне раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга:

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезнамәне раслау турында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 693 нче карары;

2) шәһәр Хакименең «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 693 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 10 июнендәге М 198 нче карары;

3) шәһәр Хакименең «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 693 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 12 февралендәге М 43 нче карары.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2018 елның 9 июлендәге
М 299 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү
һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезнамә һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 нче Указы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 нчы Указы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында (алга таба – җирле үзидарә органнары) төзелә торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияне (алга таба – комиссия) формалаштыру һәм аның эшчәнлек тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, шәһәр Уставына, әлеге Нигезнамәгә һәм башка муниципаль норматив хокукый актларга таянып эш итә.

3. Комиссиянең төп максаты булып җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләр буенча ярдәм күрсәтү тора:

1) җирле үзидарә органының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләр, шулай ук «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, башка федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу

турында таләпләр) белән билгеләнгән йөкләмәләр үтәлешен тәэмин итүдә;

2) муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) җитәкчеләре тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлешен тәэмин итүдә;

3) җирле үзидарә органында коррупциияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруда;

4) алар тарафыннан коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмаларда хезмәт килешүе төзелгән очракта, әлеге оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, муниципаль хезмәттән азат ителү көненнән башлап ике ел узганга кадәр, Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән һәм биләгәндә югары коррупция куркынычы белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфасын (алга таба – муниципаль хезмәт вазыйфалары) биләгән гражданнарга йөкләнә торган таләпләр үтәлешен тәэмин итүдә.

4. Комиссия түбәндәгеләрне үтәү белән бәйле мәсьәләләрне карый:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә мөнәсәбәтле хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр;

2) муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) җитәкчеләренә мөнәсәбәтле мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр;

3) алар тарафыннан коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмаларда хезмәт килешүе төзелгән очракта, әлеге оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, муниципаль хезмәттән азат ителү көненнән башлап ике ел узганга кадәр, муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән һәм биләгәндә югары коррупция куркынычы белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданнарга йөкләнә торган таләпләр.

5. Комиссия Татарстан Республикасының «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ санлы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 нчы Указы нигезендә эш итүче Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү буенча комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләрне карамый.

## 2 бүлек. Комиссия төзү тәртибе

6. Комиссия составы һәм аның эш тәртибе шәһәр Хакиме карары белән раслана.

Карарлар кабул иткәндә комиссиянең барлык әгъзалары да тигез

хокукка ия. Комиссия рәисе булмаган вакытта аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

1) тиешле җирле үзидарә органының җитәкчесе һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат;

2) наемга алучының вәкиле һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләтләнгән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән җирле үзидарә органының муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча структур бүлекчәсеннән коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы заты, җирле үзидарә органының юридик (хокукый) бүлекчәсеннән һәм башка бүлекчәләреннән аның җитәкчесе тарафыннан билгеләнүчеләр);

3) эшчәнлеге муниципаль хезмәт белән бәйле фәнни оешмаларның һәм урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларының вәкиле (вәкилләре).

8) Комиссия составына түбәндәгеләр кертелергә мөмкин:

1) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ санлы Законының 24 маддәсе нигезендә җирле үзидарә органы карамагында төзелгән иҗтимагый совет вәкиле;

2) муниципаль берәмлектә төзелгән ветераннар иҗтимагый оешмасы вәкиле;

3) җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эш итүче профсоюз оешмасы вәкиле.

9. Әлеге Нигезнамәнең 7 пунктының 3 пунктчасында һәм 8 пунктында күрсәтелгән затлар җирле үзидарә органы җитәкчесенең запросы нигезендә фәнни оешмалар, урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары, җирле үзидарә органы карамагында төзелгән иҗтимагый совет, муниципаль берәмлектә төзелгән ветераннар иҗтимагый оешмасы, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эш итүче профсоюз оешмасы белән килешенеп, билгеләнгән тәртиптә комиссия составына кертеләләр. Килешенү запросны алган көннән башлап 10 көн срокта гамәлгә ашырыла.

10. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләмәгән комиссия әгъзаларының саны комиссия әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

11. Комиссия составы комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясарга мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу мөмкинлеген юкка чыгара торган итеп төзелә.

12. Комиссия утырышларында киңәш хокукы белән түбәндәгеләр катнашалар:

1) комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү турында мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе һәм комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә торган комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәр кебек үк вазыйфа башкаручы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт

вазыйфасын биләүче ике муниципаль хезмәткәр;

2) җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче башка муниципаль хезмәткәрләр; муниципаль хезмәт мәсьәләләре һәм комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә ала торган белгечләр; дәүләт органнары, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынучы оешмаларның вәкилләре; комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү турында мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең, муниципаль хезмәткәрнең вәкиле, – комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең, муниципаль хезмәткәрнең үтенече нигезендә һәр очрак өчен аерым һәм комиссия утырышына кадәр өч көн алдан, комиссия рәисе карары буенча яисә комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы карары буенча.

13. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының гомуми санының өчтән ике өлешеннән күбрәк санда катнашкан очракта тулы хокуклы булып санала. Утырышларны җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

14. Комиссия әгъзасының комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда, мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки читтән шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчы ук бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

## 3 бүлек. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында мәсьәләләрне карау тәртибе

15. Комиссия утырышын үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тапшырган керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлешен тикшерү тәртибен билгеләүче муниципаль норматив хокукый акт нигезендә үткәрелгән тикшерү йомгаклары буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан түбәндәгеләрне таныклаучы тикшерү материалларын тапшыру:

- муниципаль норматив хокукый акт нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар бирү хакында;

- муниципаль хезмәткәр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрнең үтәлмәве турында;

2) җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка

хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсенә яисә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына муниципаль норматив хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә кергән:

- җирле үзидарә органы тарафыннан расланган вазыйфалар исемлегенә кертелгән җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданның, әлеге оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, муниципаль хезмәттән азат ителү көненнән башлап ике ел узганга кадәр, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яисә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирүе турында мөрәҗәгате;

- муниципаль хезмәткәрнең объектив сәбәпләр буенча хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

- муниципаль хезмәткәрнең территориясендә счетлары (кертемнәре) булган, саф акчаларын һәм байлыкларын саклау гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган чит ил дәүләте законнары нигезендә, чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан салынган арест, идарә итүне тыю белән бәйле яки аның ихтыярына яисә хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балалары ихтыярына бәйле булмаган башка шартларга бәйле рәвештә «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча чараларын һәм байлыкларны саклау, счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыруны, чит ил финанс инструментлары булдыру һәм алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

- муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китереп чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында белдерү кәгазе;

3) җирле үзидарә органы җитәкчесенең яки комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының муниципаль хезмәткәр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр үтәлешен тәэмин итүгә яисә җирле үзидарә органында коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруга кагыла торган язма гаризасы;

4) җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын башкаручы затлар һәм башка затларның чыгымнарының үз керемнәренә туры килүен тикшерү турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1 бүлегендә каралган мәгълүматларны муниципаль хезмәткәр тарафыннан дөрес булмаган яки тулы булмаган күләмдә тапшыруны раслаучы тикшерү материалларын бирү;

5) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсенең 4 бүлеге һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 маддәсе нигезендә җирле үзидарә

органына коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешмадан җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә гражданлык-хокукый килешүе төзү хакында белдерү кәгазе, әгәр әлеге оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр аның җирле үзидарә органында вазыйфа биләгән чорда башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, күрсәтелгән гражданга элек комиссия тарафыннан әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керү кире кагылган булса яисә әлеге гражданга коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә һәм коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эш башкаруга ризалык бирү хакындагы мәсьәлә комиссия тарафыннан каралмаган булса.

16. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр үткәрми.

17. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсенә яисә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына бирелә.

Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урынының адресы, муниципаль хезмәттән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешманың исеме, урнашу урыны, эшчәнлегенең характеры, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән вакытка кадәр граждан тарафыннан башкарылган вазыйфаи (хезмәт) бурычлар, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмага карата муниципаль идарә буенча функцияләр, килешү төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), аның күздә тотылган гамәлдә булу вакыты, килешү буенча эшләр (хезмәтләр) башкару (күрсәтү) өчен түләү күләме.

Җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсендә яисә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан мөрәҗәгатьне карау гамәлгә ашырыла һәм «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсендәге таләпләрне исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең эчтәлеге буенча нигезле бәяләмә әзерләнә.

18. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать муниципаль хезмәттән китүне планлаштырган муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелергә мөмкин, һәм ул әлеге Нигезнамә нигезендә комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

19. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның бишенче

абзацында күрсәтелгән белдерү кәгазе җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе яисә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы һәм белдерү кәгазен карау нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи заты тарафыннан карала.

20. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән белдерү кәгазе җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе яисә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы һәм җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданның «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсендәге таләпләрне үтәве турында нигезле бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи заты тарафыннан карала.

21. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки әлеге Нигезнамәнең 15 пунктының 2 пунктчасының бишенче абзацында һәм 5 пунктчасында күрсәтелгән белдерү кәгазьләрен карау нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерләгән вакытта, җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе яисә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне яки белдерү кәгазен биргән муниципаль хезмәткәрләр белән әңгәмә үткәрергә, алардан язмача аңлатма алырга хокуклы, ә җирле үзидарә органы җитәкчесе яки аның махсус вәкаләтләнгән урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга запрослар җибәрә ала. Мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе килгән көннән башлап җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә бирелә. Запрослар җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе кергән көннән башлап 45 көн эчендә бирелә. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артырга тиеш түгел.

22. Әлеге Нигезнамәнең 17, 19, 20 пунктларында каралган нигезле бәяләмәләр үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

1) әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче һәм бишенче абзацларында һәм 5 пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яки белдерү кәгазьләрендә бәян ителгән мәгълүмат;

2) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынучы оешмалардан алынган мәгълүмат;

3) әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче һәм бишенче абзацларында һәм 5 пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яки белдерү кәгазьләрен алдан карау йомгаклары буенча нигезле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезнамәнең 32, 35, 38 пунктлары нигезендә карарларның бирсен

яки башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.

23. Комиссия рәисе аңа җирле үзидарә органының хокукый актында каралган тәртиптә комиссия утырышы үткәрү өчен нигез булып торган мәгълүмат кергән очракта:

1) 10 көн срокта комиссия утырышының көнен билгели. Шул ук вакытта комиссия утырышы көне күрсәтелгән мәгълүматны кабул итеп алган көннән башлап 20 көннән дә соңрак вакытка билгеләнергә тиеш түгел, әлеге Нигезнамәнең 24 һәм 25 пунктларында каралган очраклардан тыш;

2) комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе каралуга мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәрнең, аның вәкиленең, комиссия әгъзаларының һәм комиссия утырышында катнашучы башка затларның җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсенә яисә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына кергән мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән танышуын оештыра;

3) әлеге Нигезнамәнең 12 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән затларны комиссия утырышына чакыру турында үтенечләрне карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүне кире кагу турында) һәм комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау турында (карауны киге кагу турында) карар кабул итә.

24. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча комиссия утырышы, керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән вакыт чыккан көннән башлап бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

25. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән белдерү кәгазе, комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

26. Комиссия утырышы, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе каралуга мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәр яки җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан катнашында уза. Муниципаль хезмәткәр яки граждан комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләве турында әлеге Нигезнамәнең 15 пунктының 2 пунктчасы нигезендә бирелә торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерү кәгазендә күрсәтә.

27. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда муниципаль хезмәткәр яки гражданнан башка үткәрелергә мөмкин:

1) әлеге Нигезнамәнең 15 пунктының 2 пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерү кәгазендә муниципаль хезмәткәр яки гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашу теләге күрсәтелмәсә;

2) комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләк белдергән һәм үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәрдар булган муниципаль хезмәткәр яки граждан комиссия утырышына килмәсә.

28. Комиссия утырышында муниципаль хезмәткәр яки җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче гражданның (аның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, асылда муниципаль хезмәткәргә белдерелгән дәгъвалар буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

29. Комиссия әгъзалары һәм комиссия утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны башкаларга җиткерергә хокуклы түгел.

30. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 1 пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирү тәртибен билгели торган муниципаль норматив хокукый акт нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелгән мәгълүматларны һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлешен дөрес һәм тулы дип билгеләргә;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында аталган муниципаль норматив хокукый акт нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелгән мәгълүматларны дөрес түгел һәм (яки) тулы түгел дип билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы куллануны тәкъдим итә.

31. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 1 пунктчаның өченче абзацында күрстелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәткәр хезмәт тәртибенә карата булган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәгән дип билгеләргә;

б) муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән дип билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне бозуны булдырмау яки муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы куллануны тәкъдим итә.

32. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

1) гражданга оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфа биләүгә һәм (яки) әлеге оешмада граждалыкн-хокукый килешүе (гражданлык-хокукый килешүләр) шартларында эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирергә, әгәр әлеге оешма белән муниципаль (административ) идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

2) гражданга оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфа биләүне һәм (яки) әлеге оешмада гражданлык-хокукый килешүе (гражданлык-хокукый килешүләр) шартларында эш башкаруны (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүне) кире кагарга, әгәр әлеге оешма белән муниципаль (административ) идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, һәм баш тартуны дәлилләргә.

33. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәткәр тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны тапшырмау сәбәбен объектив һәм нигезле дип танырга;

2) муниципаль хезмәткәр тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны тапшырмау сәбәбен нигезсез дип танырга. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыру чараларын күрүне тәкъдим итә;

3) муниципаль хезмәткәр тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны тапшырмау сәбәбен объектив түгел дип һәм әлеге мәгълүматларны тапшырудан читләшү алымы дип танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрүне тәкъдим итә.

34. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

1) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акчаларын һәм байлыкларны саклау, счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыруны, чит ил финанс инструментлары булдыру һәм алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы хәлләрне объектив һәм нигезле дип танырга;

2) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акчаларын һәм байлыкларны саклау, счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыруны, чит ил финанс инструментлары булдыру һәм алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы хәлләрне объектив түгел һәм нигезсез дип танырга. Бу очракта комиссия җитәкчегә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрүне тәкъдим итә.

35. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәткәр тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмауны танырга;

2) муниципаль хезмәткәр тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә һәм (яки) җирле үзидарә органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча яки аның килеп чыгуын булдырмау буенча чаралар күрүне тәкъдим итә;

3) муниципаль хезмәткәр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар үтәлмәде дип танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрүне тәкъдим итә.

36. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

1) «Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1 бүлеге нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны дөрес һәм тулы дип танырга;

б) «Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 1 бүлеге нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны дөрес түгел һәм тулы түгел дип танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрүне һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынган материалларны аларның компетенциясе нигезендә прокуратура органнарына һәм (яки) башка дәүләт органнарына җибәрүне тәкъдим итә.

37. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 1, 2, 4 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, нигезләр булган очракта, комиссия әлеге Нигезнамәнең 30-36 һәм 38 пунктларында каралган карарлардан тыш, башка карар кабул итәргә мөмкин. Шундый карар кабул итү нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

38. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча комиссия җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) аңа коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләргә яисә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эш башкарырга рөхсәт бирергә, әгәр әлеге оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр гражданның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

б) аның тарафыннан хезмәт килешүе шартларында коммерцияле яки

коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләү һәм (яки) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эш башкару (хезмәт күрсәтү) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсе таләпләрен боза дип билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә күрсәтелгән хәлләр турында прокуратура органнарына һәм белдерү ясаган оешмага хәбәр юллауны тәкъдим итә.

39. Әлеге Нигезнамәнең 15 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча комиссия тиешле карарны кабул итә.

40. Комиссиянең әлеге Нигезнамәнең 15 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының яшерен тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавышы буенча кабул ителә (әгәр комиссия башка карар кабул итмәсә).

41. Комиссия карарлары утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарыннан тыш, җирле үзидарә органы җитәкчесе өчен тәкъдим итү характерына ия. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри характерга ия.

42. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) комиссия утырышының датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

2) комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү турындагы мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәрнең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп;

3) муниципаль хезмәткәргә белдерелә торган дәгъвалар, аларны нигезләүче материаллар;

4) муниципаль хезмәткәрнең һәм башка затларның белдерелә торган дәгъваларның асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

5) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм алар ясаган чыгышларның кыскача эчтәлеге;

6) комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алган мәгълүматның чыганагы, мәгълүматның җирле үзидарә органына керү датасы;

7) башка мәгълүматлар;

8) тавыш бирү нәтиҗәләре;

9) карар һәм аны кабул итү нигезе.

43. Комиссиянең комиссия карары белән килешмәгән әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, бу фикерне комиссия утырышы беркетмәсенә беркетеп кую мәҗбүри һәм аның белән муниципаль хезмәткәр таныштырылырга тиеш.

44. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш көненнән

соң 7 көн срокта – җирле үзидарә органы җитәкчесенә, тулысынча яисә аннан өземтәләр рәвешендә – муниципаль хезмәткәргә, шулай ук комиссия карары буенча кызыксынучы затларга җибәрелә.

45. Җирле үзидарә органы җитәкчесе комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм үз компетенциясе чикләрендә муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча каралган җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул иткәндә андагы тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы.

Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында җирле үзидарә органы җитәкчесе үзенә комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән башлап бер ай эчендә комиссиягә язма рәвештә хәбәр итә.

Җирле үзидарә органы җитәкчесенең карары комиссиянең якын арада үткәрелә торган утырышында укып хәбәр ителә һәм фикер алышулардан башка гына исәпкә алына.

46. Комиссия муниципаль хезмәткәрнең эш итүләрендә (эш итмәвендә) дисциплинар гаеп эш билгеләре ачыклаган очракта, бу хактагы мәгълүмат муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен җирле үзидарә органы җитәкчесенә тапшырыла.

47. Комиссия муниципаль хезмәткәр тарафыннан административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булган эш итүләр фактын (эш итмәү фактын) ачыклаган очракта, комиссия рәисе әлеге эш итүләр (эш итмәү) турындагы мәгълүматны һәм әлеге фактны раслаучы документларны 3 көн срокта, ә кирәк булганда кичекмәстән хокук саклау органнарына тапшырырга тиеш.

48. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан өземтә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү турында мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәрнең шәхси делосына теркәп куела.

49. Комиссия секретареның имзасы һәм җирле үзидарә органының мөһере белән расланган комиссия карарының өземтәсе, комиссиянең тиешле утырышы үткәрелгән көннән соң килүче беренче эш көненнән дә соңга калмыйча, җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче, әлеге Нигезнамәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче абзацында күрсәтелгән хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү турында мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәргә имза куйдырып тапшырыла яки аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәрелә.

50. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышуларга чыгарыла торган материаллар белән таныштыру җирле үзидарә органының

муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча структур бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 4 бүлек. Муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турындагы хәбәрен комиссия тарафыннан карау тәртибе

51. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булып комиссиягә муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәре (алга таба – белдерү кәгазе), шулай ук нигезле бәяләмә һәм башка материаллар керү тора.

52. Әлеге Нигезнамәнең 51 пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазен алдан карау Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе (алга таба – персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе) тарафыннан гамәлгә ашырыла, белдерү кәгазен карау нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерләнә.

53. Әлеге Нигезнамәнең 52 пунктында каралган нигезле бәяләмәне әзерләгәндә персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенең вазыйфаи затлары, әлеге Нигезнамәнең 51 пункты нигезендә белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждениеләр (предприятиеләр) җитәкчеләреннән язмача аңлатма алырга хокуклы, ә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе) билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрергә мөмкин.

Белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар кергән көннән башлап җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла.

Запрослар җибәрелгән очракта белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, белдерү кәгазе кергән көннән башлап 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артмаган срокка.

54. Комиссия рәисе, аңа Башкарма комитетның хокукый актында каралган тәртиптә комиссия утырышы үткәрү өчен нигезләрне үз эченә алган мәгълүмат кергән очракта, 10 көн срокта комиссия утырышы датасын билгели. Бу очракта комиссия утырышының датасы күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән башлап 20 көннән арткан вакытка билгеләнергә тиеш түгел.

55. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышуларга чыгарыла торган материаллар белән таныштыру персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенең вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

56. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, әлеге Нигезнамәнең 51 пункты нигезендә белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе катнашында үткәрелә. Белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында белдерү кәгазендә күрсәтә.

57. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда, әлеге Нигезнамәнең 51 пункты нигезендә белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе булмаганда үткәрелә:

1) әгәр белдерү кәгазендә белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенең комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтмәләре булмаса;

2) әгәр комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр алган, белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе комиссия утырышына килмәсә.

58. Комиссия утырышында муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенең аңлатмалары тыңлана һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы материаллар карала. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының, муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенең үтенече буенча башка затлар тыңланырга һәм алар тарафыннан тапшырылган материаллар каралырга мөмкин.

59. Комиссия әгъзалары һәм комиссия утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны башкаларга җиткерергә хокуклы түгел.

60. Әлеге Нигезнамәнең 51 пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазен карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмады дип танырга;

2) белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта комиссия белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрүне тәкъдим итә;

3) белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр үтәлмәде дип танырга. Бу очракта комиссия түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

- Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенә карата конкрет җаваплылык чарасы куллануны;
- белдерү кәгазен биргән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча чаралар күрүне.

61. Комиссия муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе тарафыннан административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булган

эш итү фактын (эш итмәү фактын) ачыклаган очракта, комиссия рәисе әлеге эш итү (эш итмәү) турындагы мәгълүматны һәм әлеге фактны раслаучы документларны 3 эш көне эчендә, ә законда каралган очракларда кичекмәстән хокук саклау органнарына җибәрә.

62. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының яшерен тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавышы буенча кабул ителә (әгәр комиссия башка карар кабул итмәсә).

63. Комиссия карары утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары Башкарма комитет Җитәкчесе өчен тәкъдим итү характерына ия.

64. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышының датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы, мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп;

в) комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алган мәгълүматның чыганагы, мәгълүматның керү датасы;

г) муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенең һәм башка затларның карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм алар ясаган чыгышларның кыскача эчтәлеге;

е) башка мәгълүматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) комиссия карары һәм аны кабул итү нигезе.

65. Кабул ителгән карар белән килешмәгән комиссия әгъзалары үзләренең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, бу фикерне комиссия утырышы беркетмәсенә беркетеп кую мәҗбүри һәм аның белән муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесе таныштырылырга тиеш.

66. Комиссия карарыннан өземтә, комиссия утырышының беркетмәсе имзаланган көннән соң 5 эш көне эчендә, мәсьәлә каралуга мөнәсәбәтле муниципаль учреждение (предприятие) җитәкчесенә, шулай ук Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелә.

67. Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары — Ф.И. Андреева